Республика Татарстан
**ГЛАВА**
Пестречинского
муниципального района –
председатель Совета
Пестречинского
муниципального района
422770, с.Пестрецы, ул. Советская, 18

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы

**БАШЛЫГЫ –**

Питрәч муниципаль район
Советы рәисе
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» август, 2020 ел № 56-п

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль
районы Башкарма комитетының 2013 елның
25 ноябрендәге 2752 номерлы карары белән
расланган территорияне планлаштыру проектына
җир кишәрлекләренең техник-икътисадый
күрсәткечләрен һәм чикләрен төгәлләштерү
өлешендә үзгәрешләр кертү буенча
гавами тыңлауларны билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Уставын, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2015 елның 30 гыйнварындагы 3/224 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясендә ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы халкының хокукларын һәм мәнфәгатьләрен үтәү максатларында **карар бирәм**:

1. ТР Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 25 ноябрендәге 2752 номерлы карары (алга таба-территорияне планлаштыру проекты) белән расланган территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Территорияне планлаштыру проекты буенча ачык тыңлаулар оештыруны һәм үткәрүне Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетына һәм Богородский авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

3.Билгеләргә:

3.1. ачык тыңлауларны үткәрү датасы һәм вакыты - 23.09.2020 ел, 14.00 сәг.;

3.2. үткәрү вакыты - 1 көн;

3.3. уздыру урыны - Богородский авыл мәдәният йортының тамаша залы, ТР, Питрәч районы, Богородский авылы, Үзәк ур., 57Б;

3.4. чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү вакыты – 21.09.2020 елга кадәр;

- язмача, эш көннәрендә 08.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, 13.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башкарма комитетына түбәндәге адрес буенча мөрәҗәгать итәргә кирәк: Богородский авылы, Үзәк урамы, 57Б йорт, гражданнар өчен: фамилиясен, исемен, әтисенең исемен, яшәү урынын теркәү адресын, эш урынын һәм билгән вазыйфасын, элемтә өчен телефоннарны күрсәтеп, көн саен 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башкарма комитетына; бер төркем гражданнар – фамилияләре, исемнәре, атасының нинди дә булса иҗтимагый оешмаларга яки берләшмәләргә каравы (булган очракта), яшәү урынын теркәү адреслары, элемтә өчен телефоннар, юридик затлар өчен- оешма бланкында, җитәкченең фамилиясен, исемен, әтисенең исемен күрсәтеп.

4. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башкарма комитеты:

4.1. район «Вперед» («Алга») газетасында ачык тыңлаулар үткәрү турында мәгълүмат бастырырга;

4.2. билгеләнгән тәртип һәм әлеге карар белән билгеләнгән сроклар нигезендә территорияне планлаштыру проекты буенча ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Территорияне планлаштыру проекты буенча ачык тыңлауларга чыгарылган тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кызыксынган затлар тарафыннан Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башкарма комитетына, эш көннәрендә 8 сәгать 00 минуттан 12 сәгать 00 минутка кадәр, 2020 елның 21 сентябренә кадәр 13 сәгать 00 минуттан 16 сәгать 00 минутка кадәр, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башкарма комитеты бинасына, адрес буенча: (422774, ТР, Питрәч районы, Богородский авылы, Үзәк урамы, 57Б йорт), мәгълүмат бастырылганнан (халыкка җиткерелгәннән) язма рәвештә тапшырылырга мөмкин.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов